СОВЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 18 » декабрь 2020 ел** **№ 18**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 22 октябрендәге 91 номерлы (2018 елның 21 декаберендәге №103 үзгәрешләр белән) Яңа Кенәр авыл жирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Прокуратура күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатыннан һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставына таянып, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2018 елның 22 октябрендәге 91 номерлы (2018 елның 21 декаберендәге №103 үзгәрешләр белән) карары белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«4 статья. Гавами тыңлаулар инициаторлары**

Гавами тыңлаулар халык, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы (алга таба - Совет), авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык), үз вәкаләтләрен Регламент нигезендә контракт буенча гамәлгә ашыручы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - БК җитәкчесе) инициативасы белән үткәрелә.»;

2) 5 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Совет карары белән билгеләнә.

Җирлек башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Гавами тыңлаулар Россия Федерациясе законнары буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.»;

3) 6 статьяның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны дәлилле нигезләп, массакүләм мәгълүмат чараларында, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм (яисә) башка мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ